СОВЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦПИАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты,
Үрнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

**«04» октябрь 2016 ел** **№15**

**Үрнәк авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Үрнәк авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Үрнәк авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Үрнәк авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2016 елның 20 ноябренә Үрнәк авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«2017 елда Үрнәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенчатеркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә (түләү күләме 250 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, Бөек ватан сугышы ветераннарыннан тыш) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

- Үрнәк авыл җирлеге составына керүче юлларга вак таш салу, чокырлар ремонтлау, торак пунктларда дренаж торбаларын урнаштыру:

Үрнәк авылы( Көнчыгыш ур., 11 -18й., Төньяк ур., 1-7 й., Болын ур., 1-6 й., Елга арты ур., 1-3 й., Урман ур., 2-8 й., Наратлы ур., 1-8 й., Тау асты ур., 1-10 й., Үзәк ур.. 1-11 й., Көнбатыш ур., 19-28 й.); Түбән Пошалым авылы (Комсомол ур., 1-54 й., Пионер ур., 2-19 й.); Югары Пошалым авылы (Сәләхова ур., 2-8, 42-43 й., Тукай ур., 18-28 й., Ленин ур., 1-19 й., Мичурин ур., 1-18 й., Урал ур., 1-6 й.); Урта Пошалым авылы ( Х.Такташ ур., 3-25 й., Сәйдәш ур., 1-21 й., Вахитов ур., 1 й.); Көтек авылы (Комсомол ур., 20-28 й., Гагарин ур., 33-42 й., Мәктәп ур.,60-65 й.); Казанбаш авылы (Мәктәп ур., 92-104 й., Җиңү ур., 37-40 й., Яшьләр ур., 126-134 й., Азин ур., 195-216 й., Киров ур., 2-26 й., Тынычлык ур., 135-139 й., М.Хәстиев ур., 69-124 й.); Дүртөйле авылы (Күперле ур., 1-14 й.);Апайкин Гарь авылы (Үзәк ур., 20-й.) Казанка авылы (Җиңү ур., 1-10 й.); Тылангыр авылы (Пионер ур., 1-14 й., Татарстан ур. 19-30 й.); Күлтәс авылы (Р.Мөбәрәкшин ур., 1-34 й., Г.Кәбиров ур., 1-39 й., Зиятдиновлар ур., 1-25 й.); Гарталовка авылы (Урман ур., 10-17 й.);

- Тылангыр авылында җәяүлеләр күперен ремонтлау;
- зиратларны төзекләндерү:

Иске Төрнәле авылы (зират коймасын алыштыру һәм яшел мәйданнарны санитар кисү); Алга- Көек авылы (зират коймасын алыштыру һәм яшел мәйданнарны санитар кисү); Үрнәк авылы (зират коймасын алыштыру); Күлтәс авылы (зират коймасын алыштыру һәм яшел мәйданнарны санитар кисү);

-авылларда яктырткычларны, лампаларны, бишенче линияне, хисаплау төеннәрен алмаштыру һәм урнаштыру: Үрнәк авылы, Казанка авылы, Апайкина Гарь авылы, Урта Пошалым авылы, Югары Пошалым авылы, Түбән Пошалым авылы, Күлтәс авылы, Казанбаш авылы, Иске Төрнәле авылы, Кече Төрнәле авылы, Алга-Көек авылы, Көтек авылы;

- авылларда чишмәләрне төзекләндерү: Кече Төрнәле авылы, Тылангыр авылы, Казанка авылы.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

әйе юк

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы, Арча районы, Үрнәк авылы, Урман ур., 44А йорт, Арча районы, Казанбаш авылы, Киров ур., 49 йорт, Арча районы, Урта Пошалым авылы, Вахитов ур., 15 йорт) мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы И.Р.Камалетдинов